РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

29.01.2021 № 84-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Җирләү һәм күмү эше турында”гы 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында “Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында”гы 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “2021 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында”гы 2021 елның 28 гыйнварындагы 73 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елның 1 февраленнән, Саба муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен, 1,2,3 кушымталар нигезендә, 6 424,98 сум күләмендә билгеләргә.
2. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында”гы 2020 елның 31 гыйнварындагы 134-п номерлы карарының 1 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар 2021 елның 1 февраленнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарны “Саба таңнары” район газетасында, Интернет челтәрендә – Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
______________________
______________________
номерлы карарына
1 Кушымта

**2021 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында, авыл җирлекләрен дә кертеп, җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе**

| № п/п | Авыл җирлекләре исеме | Җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | Арташ | 6 424,98 |
| 2 | Олы Кибәче | |
| 3 | Олы Нырты | |
| 4 | Олы Шыңар | |
| 5 | Югары Симет | |
| 6 | Явлаштау | |
| 7 | Эзмә | |
| 8 | Иштуган | |
| 9 | Килдебәк | |
| 10 | Курсабаш | |
| 11 | Түбән Шытсу | |
| 12 | Мишә | |
| 13 | Мичән | |
| 14 | Саба шәһәр җирлеге | |
| 15 | Сатыш | |
| 16 | Иске Икшермә | |
| 17 | Тимершык | |
| 18 | Шәмәрдән | |
| 19 | Шекше | |
| 20 | Юлбат | |

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
______________________
______________________
номерлы карарына
2 Кушымта

**2021 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләргә**
**ТАРИФЛАР**

| Хезмәтнең исеме | Хезмәтнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җеназа агачын - табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2 924,27 |
| 3. Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка илтү | 582,85 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2 917,86 |
| **Барлыгы** | **6 424,98** |

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
_______________________
_______________________
номерлы карарына
3 Кушымта

**2021 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләргә**
**ТАРИФЛАР**

| Хезмәтнең исеме | Хезмәтнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Мәетне кәфенләү (төрү) | 255,66 |
| 3.  Җеназа агачын (табутны) һәм җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2 668,61 |
| 4. Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка илтү | 582,85 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2 917,86 |
| **Барлыгы** | **6 424,98** |